ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.09.2026 Олы Кайбыч ав. № 444

16:21:010107:404 кадастр номерлы җир кишәрлеген файдаланунын шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

Халыкның җир кишәрлекләре хокукына ия булучыларының тормыш эшчәнлеген, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен уңай шартларга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 16:21:010107:404 кадастр номерлы, 500 кв.м мәйданлы, Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы, Олы Кайбыч авыл җирлеге, Олы Кайбыч ав., Северная ур., 39 А - «Җәмәгать туклануы» адресы буенча универсаль торак зонасы зонасында (Ж-У) урнашкан Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча (кушымта) җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. 1 октябрьдә 10.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й. адресы буенча урнашкан иҗтимагый үзәк бинасында 16:21:010107:404 кадастр номерлы җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

3. 16:21:010107:404 кадастр номерлы җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты материаллары белән (текст һәм график өлеш) эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт, 2 кат, 209 кабинет адресы буенча танышырга мөмкин.

3.1. 16:21:010107:404 кадастр номерлы җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җыю урыны итеп Татарстан Республикасы, Кайбыч

районы, Олы Кайбыч авылы, Краяшлы бульвар, 7 йорт, 2  кат, 209 кабинет адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеген билгеләргә.

4. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә:

- 16:21:010107:404 кадастр номерлы җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында боерык проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга;

- әлеге карарны Татарстан Республикасы  хокукый мәгълүматы порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.С. Шакировка йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026е. 18.09. 444 номерлы
карарына кушымта

МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРОЕКТ**

№__________

П Р И К А З Б О Е Р Ы К

«_____»______________, 20__

**Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе тәкъдимнәрен исәпкә алып, карар бирәм:

1. Гыйсмәтуллин Илгиз Ирек улына 16:21:010107:404 кадастр номерлы, 500 кв.м мәйданлы, Татарстан Республикасы, Кайбыч муниципаль районы, Олы Кайбыч авыл җирлеге, Олы Кайбыч ав., Северная ур., 39А адресы - «Җәмәгать туклануы» адресы буенча универсаль торак зонасы зонасында (Ж-У) урнашкан Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Олы Кайбыч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирергә.

2. Массакүләм мәгълүмат чаралары (Р.Ж.Зәйнуллинага) белән хезмәттәшлек итү секторына әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү бүлегенә (А.А.Шәйдуллинага) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгару өчен җибәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Территорияләрне үстерү департаменты Җитәкчесе** **А.И. Әхмәтҗанов**